**ЗАКОН**
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

# О порядке официального опубликования и вступления в силу законов Республики Татарстан, постановлений Государственного Совета Республики Татарстан и его Президиума, нормативных правовых актов Президента Республики Татарстан, Кабинета Министров Республики Татарстан, иных органов исполнительной власти Республики Татарстан

Принят
Государственным Советом
Республики Татарстан
21 апреля 2022 года

## Статья 1. **Предмет регулирования настоящего Закона**

Настоящий Закон определяет порядок официального опубликования и вступления в силу законов Республики Татарстан и имеющих нормативный характер постановлений Государственного Совета Республики Татарстан, нормативных правовых актов Президента Республики Татарстан, Кабинета Министров Республики Татарстан, иных органов исполнительной власти Республики Татарстан (далее – нормативные правовые акты Республики Татарстан), а также не имеющих нормативного характера постановлений Государственного Совета Республики Татарстан и постановлений его Президиума.

## Статья 2. **Общие требования к официальному опубликованию нормативных правовых актов Республики Татарстан**

1. На территории Республики Татарстан применяются только те нормативные правовые акты Республики Татарстан, которые официально опубликованы.

2. Официальным опубликованием нормативного правового акта Республики Татарстан считается первая публикация его полного текста в газетах «Республика Татарстан» и «Ватаным Татарстан», журнале «Собрание законодательства Республики Татарстан» или первое размещение (опубликование) на «Официальном портале правовой информации Республики Татарстан» (PRAVO.TATARSTAN.RU) либо на «Официальном интернет-портале правовой информации» (www.pravo.gov.ru). Официальными являются также тексты

нормативных правовых актов Республики Татарстан, включенные в интегрированный полнотекстовый банк правовой информации (эталонный банк данных правовой информации).

3. Тексты нормативных правовых актов Республики Татарстан подлежат официальному опубликованию на татарском и русском языках и имеют одинаковую юридическую силу.

Статья 3. **Официальное опубликование и вступление в силу законов Республики Татарстан**

1. Законы Республики Татарстан обнародуются Президентом Республики Татарстан путем их официального опубликования.

2. Принятый Государственным Советом Республики Татарстан закон Республики Татарстан в течение 14 календарных дней направляется Президенту Республики Татарстан.

3. Президент Республики Татарстан подписывает и обнародует закон Республики Татарстан либо отклоняет указанный закон в течение 14 календарных дней с момента его поступления.

4. Закон Республики Татарстан вступает в силу одновременно на всей территории Республики Татарстан по истечении 10 дней после дня его официального опубликования, если федеральным законом и (или) самим законом Республики Татарстан не установлен иной порядок вступления его в силу.

5. Срок вступления в силу законов Республики Татарстан, затрагивающих права и свободы человека и гражданина, не может составлять менее 10 дней после дня их официального опубликования.

Статья 4. **Официальное опубликование и вступление в силу постановлений Государственного Совета Республики Татарстан и его Президиума**

1. Имеющие нормативный характер постановления Государственного Совета Республики Татарстан подлежат официальному опубликованию не позднее 10 дней после дня их принятия. Не имеющие нормативного характера постановления Государственного Совета Республики Татарстан, постановления Президиума Государственного Совета Республики Татарстан могут быть официально опубликованы в порядке и сроки, предусмотренные для постановлений Государственного Совета Республики Татарстан, имеющих нормативный характер.

2. Постановления Государственного Совета Республики Татарстан и его Президиума вступают в силу со дня их принятия, если в указанных актах не установлен иной порядок вступления их в силу.

3. Срок вступления в силу постановлений Государственного Совета Республики Татарстан, имеющих нормативный характер и затрагивающих права и

свободы человека и гражданина, не может составлять менее 10 дней после дня их официального опубликования.

Статья 5. **Официальное опубликование и вступление в силу нормативных правовых актов Президента Республики Татарстан, Кабинета Министров Республики Татарстан, иных органов исполнительной власти Республики Татарстан**

1. Нормативные правовые акты Президента Республики Татарстан, Кабинета Министров Республики Татарстан подлежат официальному опубликованию в течение 10 дней после дня их издания.

2. Нормативные правовые акты иных органов исполнительной власти Республики Татарстан, прошедшие в установленном порядке государственную регистрацию, подлежат официальному опубликованию в течение 10 дней после дня их государственной регистрации. Порядок государственной регистрации нормативных правовых актов органов исполнительной власти Республики Татарстан устанавливается Кабинетом Министров Республики Татарстан.

3. Не подлежат опубликованию нормативные правовые акты Президента Республики Татарстан, Кабинета Министров Республики Татарстан, иных органов исполнительной власти Республики Татарстан или отдельные положения указанных актов, содержащие сведения, составляющие государственную тайну, и иные сведения, не подлежащие разглашению в соответствии с законодательством Российской Федерации и законодательством Республики Татарстан.

4. Вопросы, связанные с порядком официального опубликования нормативных правовых актов Президента Республики Татарстан в части, не регламентированной настоящим Законом, определяются Президентом Республики Татарстан.

5. Вопросы, связанные с порядком официального опубликования нормативных правовых актов Кабинета Министров Республики Татарстан, иных органов исполнительной власти Республики Татарстан в части, не регламентированной настоящим Законом, определяются Кабинетом Министров Республики Татарстан.

6. Нормативные правовые акты Президента Республики Татарстан, Кабинета Министров Республики Татарстан, иных органов исполнительной власти Республики Татарстан вступают в силу со дня их официального опубликования, если данными актами не предусмотрен иной порядок вступления их в силу.

7. Срок вступления в силу нормативных правовых актов Президента Республики Татарстан, Кабинета Министров Республики Татарстан, иных органов исполнительной власти Республики Татарстан, затрагивающих права и свободы человека и гражданина, не может составлять менее 10 дней после дня их официального опубликования.

Статья 6. **Иные способы опубликования и доведения до всеобщего сведения нормативных правовых актов Республики Татарстан**

1. Законы Республики Татарстан подлежат размещению на официальном сайте Президента Республики Татарстан, а иные нормативные правовые акты Республики Татарстан – на официальных сайтах принявших их органов государственной власти Республики Татарстан в информационно-телекоммуникационной сети «Интернет» в сроки, предусмотренные для их официального опубликования.

2. Нормативные правовые акты Республики Татарстан могут быть опубликованы в иных печатных изданиях, помимо указанных в части 2 статьи 2 настоящего Закона, а также доведены до всеобщего сведения (обнародованы) по телевидению и радио, разосланы государственным органам, органам местного самоуправления, должностным лицам, организациям, переданы по каналам связи, распространены в машиночитаемой форме.

Статья 7. **Реквизиты закона Республики Татарстан, иного нормативного правового акта Республики Татарстан, указываемые при официальном опубликовании**

1. При официальном опубликовании закона Республики Татарстан указываются наименование закона, дата его принятия Государственным Советом Республики Татарстан, должностное лицо, его подписавшее, место и дата его подписания, регистрационный номер.

2. При официальном опубликовании иного нормативного правового акта Республики Татарстан указываются его наименование, должностное лицо, его подписавшее, место и дата его принятия (издания), регистрационный номер.

Статья 8. **Заключительные положения**

1. Постановления Государственного Совета Республики Татарстан и его Президиума направляются для официального опубликования Аппаратом Государственного Совета Республики Татарстан.

2. «Ведомости Государственного Совета Татарстана» являются официальным изданием Государственного Совета Республики Татарстан, предназначенным для публикации актов Государственного Совета Республики Татарстан и его Президиума, а также иных актов. Структура «Ведомостей Государственного Совета Татарстана», порядок их подготовки, выпуска и распространения определяются Президиумом Государственного Совета Республики Татарстан.

Статья 9. **Признание утратившими силу отдельных законодательных актов Республики Татарстан**

Признать утратившими силу:

1) Закон Республики Татарстан от 31 октября 2002 года № 21-ЗРТ «О порядке опубликования и вступления в силу законов и иных нормативных правовых актов Республики Татарстан по вопросам защиты прав и свобод человека и гражданина» (Ведомости Государственного Совета Татарстана, 2002, № 11);

2) Закон Республики Татарстан от 11 января 2003 года № 1-ЗРТ «О внесении дополнения в статью 5 Закона Республики Татарстан «О порядке опубликования и вступления в силу законов и иных нормативных правовых актов Республики Татарстан по вопросам защиты прав и свобод человека и гражданина» (Ведомости Государственного Совета Татарстана, 2003, № 1);

3) Закон Республики Татарстан от 6 августа 2003 года № 27-ЗРТ «О порядке опубликования и вступления в силу законов Республики Татарстан и других актов, принятых Государственным Советом Республики Татарстан и его Президиумом» (Ведомости Государственного Совета Татарстана, 2003, № 8);

4) Закон Республики Татарстан от 29 июля 2009 года № 32-ЗРТ «О внесении изменения в часть вторую статьи 5 Закона Республики Татарстан «О порядке опубликования и вступления в силу законов и иных нормативных правовых актов Республики Татарстан по вопросам защиты прав и свобод человека и гражданина» (Ведомости Государственного Совета Татарстана, 2009, № 7 – 8 (I часть);

5) Закон Республики Татарстан от 30 июня 2011 года № 34-ЗРТ «О внесении изменения в статью 6 Закона Республики Татарстан «О порядке опубликования и вступления в силу законов Республики Татарстан и других актов, принятых Государственным Советом Республики Татарстан и его Президиумом» (Ведомости Государственного Совета Татарстана, 2011, № 6 (I часть);

6) Закон Республики Татарстан от 11 апреля 2013 года № 29-ЗРТ «О внесении изменений в Закон Республики Татарстан «О порядке опубликования и вступления в силу законов Республики Татарстан и других актов, принятых Государственным Советом Республики Татарстан и его Президиумом» (Ведомости Государственного Совета Татарстана, 2013, № 4 (I часть);

7) Закон Республики Татарстан от 17 июля 2013 года № 67-ЗРТ «О внесении изменения в статью 5 Закона Республики Татарстан «О порядке опубликования и вступления в силу законов и иных нормативных правовых актов Республики Татарстан по вопросам защиты прав и свобод человека и гражданина» (Ведомости Государственного Совета Татарстана, 2013, № 7);

8) Закон Республики Татарстан от 11 апреля 2014 года № 21-ЗРТ «О внесении изменения в статью 5 Закона Республики Татарстан «О порядке опубликования и вступления в силу законов и иных нормативных правовых актов

Республики Татарстан по вопросам защиты прав и свобод человека и гражданина» (Ведомости Государственного Совета Татарстана, 2014, № 4);

9) Закон Республики Татарстан от 24 июля 2014 года № 73-ЗРТ «О внесении изменений в статью 5 Закона Республики Татарстан «О порядке опубликования и вступления в силу законов и иных нормативных правовых актов Республики Татарстан по вопросам защиты прав и свобод человека и гражданина» и Закон Республики Татарстан «О порядке опубликования и вступления в силу законов Республики Татарстан и других актов, принятых Государственным Советом Республики Татарстан и его Президиумом» (Ведомости Государственного Совета Татарстана, 2014, № 7);

10) Закон Республики Татарстан от 25 декабря 2014 года № 131-ЗРТ «О внесении изменений в статью 5 Закона Республики Татарстан «О порядке опубликования и вступления в силу законов и иных нормативных правовых актов Республики Татарстан по вопросам защиты прав и свобод человека и гражданина» и статьи 4, 5 Закона Республики Татарстан «О порядке опубликования и вступления в силу законов Республики Татарстан и других актов, принятых Государственным Советом Республики Татарстан и его Президиумом» (Ведомости Государственного Совета Татарстана, 2014, № 12 (IV часть);

11) Закон Республики Татарстан от 29 сентября 2016 года № 71-ЗРТ «О внесении изменений в статью 5 Закона Республики Татарстан «О порядке опубликования и вступления в силу законов и иных нормативных правовых актов Республики Татарстан по вопросам защиты прав и свобод человека и гражданина» и статьи 4, 7 Закона Республики Татарстан «О порядке опубликования и вступления в силу законов Республики Татарстан и других актов, принятых Государственным Советом Республики Татарстан и его Президиумом» (Собрание законодательства Республики Татарстан, 2016, № 25 (часть I);

12) Закон Республики Татарстан от 29 апреля 2019 года № 37-ЗРТ «О внесении изменения в статью 4 Закона Республики Татарстан «О порядке опубликования и вступления в силу законов Республики Татарстан и других актов, принятых Государственным Советом Республики Татарстан и его Президиумом» (Собрание законодательства Республики Татарстан, 2019, № 40 (часть I).

Статья 10. **Вступление в силу настоящего Закона**

Настоящий Закон вступает в силу с 1 июня 2022 года.

Президент
Республики Татарстан — Р.Н. Минниханов

Казань, Кремль
29 апреля 2022 года
№ 24-ЗРТ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# Татарстан Республикасы законнарын, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы һәм аның Президиумы карарларын, Татарстан Республикасы Президенты, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең башка органнары норматив хокукый актларын рәсми бастырып чыгару һәм аларның үз көченә керү тәртибе турында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2022 елның 21 апрелендә
кабул ителде

1 статья. **Әлеге Законның җайга салу предметы**

Әлеге Закон Татарстан Республикасы законнарын һәм норматив характердагы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карарларын, Татарстан Республикасы Президенты, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең башка органнары норматив хокукый актларын (алга таба – Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары), шулай ук норматив характерда булмаган Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карарларын һәм аның Президиумы карарларын бастырып чыгару һәм аларның үз көченә керү тәртибен билгели.

2 статья. **Татарстан Республикасы норматив хокукый актларын рәсми бастырып чыгаруга гомуми таләпләр**

1. Татарстан Республикасы территориясендә рәсми бастырып чыгарылган Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары гына кулланыла.
2. Татарстан Республикасы норматив хокукый актын рәсми бастырып чыгару дип аның тулы текстын «Республика Татарстан» һәм «Ватаным Татарстан» газеталарында, «Татарстан Республикасы законнар җыелмасы» журналында беренче мәртәбә бастырып чыгару яисә «Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталы»нда (PRAVO.TATARSTAN.RU) йә «Рәсми хокукый мәгълүмат интернет порталы»нда (www.pravo.gov.ru) беренче мәртәбә урнаштыру (бастырып чыгару) санала. Интеграцияләнгән тулы текстлы хокукый мәгълүмат банкына (хокукый мәгълүматның эталон белешмәләр банкына) кертелгән Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары текстлары шулай ук рәсми була.

3. Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары текстлары татар һәм рус телләрендә рәсми бастырып чыгарылырга тиеш, алар бер үк юридик көчкә ия була.

3 статья. **Татарстан Республикасы законнарын рәсми бастырып чыгару һәм аларның үз көченә керүе**

1. Татарстан Республикасы законнары аларны рәсми бастырып чыгару юлы белән Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан халыкка җиткерелә.
2. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан кабул ителгән Татарстан Республикасы законы 14 календарь көн эчендә Татарстан Республикасы Президентына җибәрелә.
3. Татарстан Республикасы Президенты Татарстан Республикасы законын имзалый һәм халыкка җиткерә йә күрсәтелгән законны кергән вакытыннан алып 14 календарь көн эчендә кире кага.
4. Татарстан Республикасы законы, әгәр федераль законда һәм (яисә) Татарстан Республикасы законының үзендә аның үз көченә керүнең башка тәртибе билгеләнмәгән булса, рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач Татарстан Республикасының барлык территориясендә бер үк вакытта үз көченә керә.
5. Кеше һәм граждан хокукларына һәм ирекләренә кагылышлы Татарстан Республикасы законнарының үз көченә керү срогы аларның рәсми басылып чыккан көненнән соң кимендә 10 көн тәшкил итәргә тиеш.

4 статья. **Татарстан Республикасы Дәүләт Советы һәм аның Президиумы карарларын рәсми бастырып чыгару һәм аларның үз көченә керүе**

1. Норматив характердагы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карарлары алар кабул ителгән көннән соң 10 көннән дә соңга калмыйча рәсми бастырып чыгарылырга тиеш. Норматив характерда булмаган Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карарлары, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы карарлары норматив характердагы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карарлары өчен каралган тәртиптә һәм срокларда рәсми бастырып чыгарылырга мөмкин.
2. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы һәм аның Президиумы карарлары, әгәр күрсәтелгән актларда аларның үз көченә керүнең башка тәртибе билгеләнмәгән булса, кабул ителгән көненнән үз көченә керәләр.
3. Кеше һәм граждан хокукларына һәм ирекләренә кагылышлы норматив характердагы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карарларының үз көченә керү срогы аларның рәсми басылып чыккан көненнән соң кимендә 10 көн тәшкил итәргә тиеш.

5 статья. **Татарстан Республикасы Президенты, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең башка органнары норматив хокукый актларын рәсми бастырып чыгару һәм аларның үз көченә керүе**

1. Татарстан Республикасы Президенты, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты норматив хокукый актлары аларны чыгарган көннән соң 10 көн эчендә рәсми бастырып чыгарылырга тиеш.

2. Татарстан Республикасы башкарма хакимияте башка органнарының дәүләт теркәвенә билгеләнгән тәртиптә алынган норматив хокукый актлары алар дәүләт теркәвенә алынган көннән соң 10 көн эчендә рәсми бастырып чыгарылырга тиеш. Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары норматив хокукый актларын дәүләт теркәвенә алу тәртибе Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнә.

3. Дәүләт серен тәшкил итүче белешмәләр һәм Россия Федерациясе законнары һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә таратылырга тиеш булмаган башка белешмәләр кертелгән Татарстан Республикасы Президенты, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең башка органнары норматив хокукый актлары яисә әлеге актларның аерым нигезләмәләре бастырып чыгарылырга тиеш түгел.

4. Әлеге Закон белән регламентлаштырылмаган өлештә Татарстан Республикасы Президенты норматив хокукый актларын рәсми бастырып чыгару тәртибенә бәйле мәсьәләләр Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан билгеләнә.

5. Әлеге Закон белән регламентлаштырылмаган өлештә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең башка органнары норматив хокукый актларын рәсми бастырып чыгару тәртибенә бәйле мәсьәләләр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнә.

6. Татарстан Республикасы Президенты, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең башка органнары норматив хокукый актлары, әгәр бу актларда аларның үз көченә керүнең башка тәртибе каралмаган булса, рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керәләр.

7. Кеше һәм граждан хокукларына һәм ирекләренә кагылышлы Татарстан Республикасы Президенты, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең башка органнары норматив хокукый актларының үз көченә керү срогы аларның рәсми басылып чыккан көненнән соң кимендә 10 көн тәшкил итәргә тиеш.

6 статья. **Татарстан Республикасы норматив хокукый актларын бастырып чыгаруның һәм гомуми игътибарга җиткерүнең башка ысуллары**

1. Татарстан Республикасы законнары Татарстан Республикасы Президентының рәсми сайтында, ә Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары аларны кабул иткән Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтларында әлеге законнарны һәм актларны рәсми бастырып чыгару өчен каралган срокларда урнаштырылырга тиеш.

2. Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары, әлеге Законның 2 статьясындагы 2 өлешендә күрсәтелгән басмалардан тыш, башка матбугат басмаларында да бастырып чыгарылырга, шулай ук гомуми игътибарга (халыкка) телевидение һәм радио аша җиткерелергә, дәүләт органнарына, җирле үзидарә органнарына, вазыйфаи затларга, оешмаларга җибәрелергә, элемтә каналлары буенча тапшырылырга, машина тарафыннан укыла торган рәвештә таратылырга мөмкин.

7 статья. **Татарстан Республикасы законының, Татарстан Республикасы башка норматив хокукый актының рәсми бастырып чыгарганда күрсәтелә торган реквизитлары**

1. Татарстан Республикасы законын рәсми бастырып чыгарганда законның исеме, аны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан кабул итү датасы, аны имзалаган вазыйфаи зат, аны имзалау урыны һәм датасы, теркәү номеры күрсәтелә.

2. Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актын рәсми бастырып чыгарганда аның исеме, аны имзалаган вазыйфаи зат, аны кабул итү (чыгару) урыны һәм датасы, теркәү номеры күрсәтелә.

8 статья. **Йомгаклау нигезләмәләре**

1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы һәм аның Президиумы карарлары рәсми бастырып чыгару өчен Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппараты тарафыннан җибәрелә.

2. «Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы» Татарстан Республикасы Дәүләт Советы һәм аның Президиумы актларын, шулай ук башка актларны бастырып чыгару өчен билгеләнгән Татарстан Республикасы Дәүләт Советының рәсми басмасы булып тора. «Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы» структурасы, аны әзерләү, чыгару һәм тарату тәртибе Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы тарафыннан билгеләнә.

9 статья. **Татарстан Республикасы аерым закон актларының үз көчен югалтуын тану**

Түбәндәгеләрне үз көчен югалткан дип танырга:

1) «Кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен яклау мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы законнарын һәм башка норматив хокукый актларын бастырып чыгару һәм аларның үз көченә керү тәртибе турында» 2002 елның 31 октябрендәге 21-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2002, № 11);

2) «Кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен яклау мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы законнарын һәм башка норматив хокукый актларын бастырып чыгару һәм аларның үз көченә керү тәртибе турында» Татарстан Республикасы Законының 5 статьясына өстәмә кертү хакында» 2003 елның 11 гыйнварындагы 1-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2003, № 1);

3) «Татарстан Республикасы законнарын, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы һәм аның Президиумы кабул иткән башка актларны бастырып чыгару һәм аларның үз көченә керү тәртибе турында» 2003 елның 6 августындагы 27-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2003, № 8);

4) «Кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен яклау мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы законнарын һәм башка норматив хокукый актларын бастырып чыгару һәм аларның үз көченә керү тәртибе турында» Татарстан Республикасы Законының 5 статьясындагы икенче өлешенә үзгәреш кертү хакында» 2009 елның 29 июлендәге 32-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2009, № 7 – 8 (I өлеш);

5) «Татарстан Республикасы законнарын, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы һәм аның Президиумы кабул иткән башка актларны бастырып чыгару һәм аларның үз көченә керү тәртибе турында» Татарстан Республикасы Законының 6 статьясына үзгәреш кертү хакында» 2011 елның 30 июнендәге 34-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2011, № 6 (I өлеш);

6) «Татарстан Республикасы законнарын, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы һәм аның Президиумы кабул иткән башка актларны бастырып чыгару һәм аларның үз көченә керү тәртибе турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2013 елның 11 апрелендәге 29-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2013, № 4 (I өлеш);

7) «Кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен яклау мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы законнарын һәм башка норматив хокукый актларын бастырып чыгару һәм аларның үз көченә керү тәртибе турында» Татарстан Республикасы Законының 5 статьясына үзгәреш кертү хакында» 2013 елның 17 июлендәге 67-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2013, № 7);

8) «Кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен яклау мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы законнарын һәм башка норматив хокукый актларын бастырып чыгару һәм аларның үз көченә керү тәртибе турында» Татарстан Республикасы Законының 5 статьясына үзгәреш кертү хакында» 2014 елның 11 апрелендәге 21-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2014, № 4);

9) «Кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен яклау мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы законнарын һәм башка норматив хокукый актларын бастырып чыгару һәм аларның үз көченә керү тәртибе турында» Татарстан Республикасы Законының 5 статьясына һәм «Татарстан Республикасы законнарын, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы һәм аның Президиумы кабул иткән башка актларны бастырып чыгару һәм аларның үз көченә керү тәртибе турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2014 елның 24 июлендәге 73-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2014, № 7);

10) «Кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен яклау мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы законнарын һәм башка норматив хокукый актларын бастырып чыгару һәм аларның үз көченә керү тәртибе турында» Татарстан Республикасы Законының 5 статьясына һәм «Татарстан Республикасы законнарын, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы һәм аның Президиумы кабул иткән башка актларны бастырып чыгару һәм аларның үз көченә керү тәртибе турында» Татарстан Республикасы Законының 4, 5 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 2014 елның 25 декабрендәге 131-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2014, № 12 (IV өлеш);

11) «Кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен яклау мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы законнарын һәм башка норматив хокукый актларын бастырып чыгару һәм аларның үз көченә керү тәртибе турында» Татарстан Республикасы Законының 5 статьясына һәм «Татарстан Республикасы законнарын, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы һәм аның Президиумы кабул иткән башка актларны бастырып чыгару һәм аларның үз көченә керү тәртибе турында» Татарстан Республикасы Законының 4, 7 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 2016 елның 29 сентябрендәге 71-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын (Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 25 (I өлеш);

12) «Татарстан Республикасы законнарын, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы һәм аның Президиумы кабул иткән башка актларны бастырып чыгару һәм аларның үз көченә керү тәртибе турында» Татарстан Республикасы Законының 4 статьясына үзгәреш кертү хакында» 2019 елның 29 апрелендәге 37-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын (Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2019, № 40 (I өлеш).

10 статья. **Әлеге Законның үз көченә керүе**

Әлеге Закон 2022 елның 1 июненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты — Р.Н. Миңнеханов

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ * АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2022 ел, 29 апрель
№ 24-ТРЗ